Әлки муниципаль районы Советы
Татарстан Республикасы
**КАРАРЫ**

204№ 2018 нче елның 17 нче декабреннән

2017елның 15 ноябрендәге 134 номерлы
"Муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру,
алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау
турында (җир кишәрлекләреннән тыш),муниципаль
районы милкендә булган, өченче затларның
хокукларыннан ирекле (мөлкәти хокуклардан тыш)
кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече
һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм
инфраструктурасын төзи торган оешмаларга
файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан
Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә
үзгәрешләр кертү хакында" Әлки муниципаль районы
Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 3 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017елның 15 ноябрендәге 134 номерлы "Муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында (җир кишәрлекләреннән тыш),муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан ирекле (мөлкәти хокуклардан тыш) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Әлки муниципаль районы Совет карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1.3 пункт. Тәртипнең 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм Арендалана торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүсез читләштерү исемлегеннән тыш һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда сату тыела. Күрсәтелгән мөлкәткә карата шулай ук алардан файдалану хокукларын бозу, алардан файдалану хокукын залог итеп тапшыру һәм мондый мөлкәт белән файдалану хокукларын теләсә кайсы башка хуҗалык эшчәнлеге субъектларының устав капиталына кертү, өченче затларга мондый милекне арендалау килешүләре буенча хокук һәм бурычларны тапшыру (яңадан наймга бирү), 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы "Көндәшлекне яклау турында" Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган мөлкәт бирелә торган очракта, мондый мөлкәт кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан субарендага тапшырудан тыш тыела."

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми PRAVO.TATARSTAN .RU. порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Даими комитетына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы башлыгы,
Әлки муниципаль районы Советы рәисе Никошин А.Ф.